Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР
05.04.2023 ел №136

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 03.10.2022 ел, №98 карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман районы Прокуратурасы 2023 елның 02 мартындагы 02-01-21/2023 номерлы мәгълүмат нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 03.10.2022 ел, №98 карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 статьясындагы 3 пунктына «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Нигезләмәнең 18 статьясындагы 1 пунктының б пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм http:/ www.sarmanovo.tatar.ruвеб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
СоветыРәисе Р.Ә.Кәримов